# “Баш иябез Бөек елларга”

# 1941-1945

## Бөек Ватан сугышы елларындагы тыл ветераннары турында хәтер альбомы

**Шәһәр тибындагы Байлар Сабасы бистәсе ветераннары**

# Шакирова (Бикмөхәммәтова) Әминә Хаҗи кызы





Шакирова Әминә Хаҗи кызы Саба районы Байлар Сабасы авылында 1931 елның 15 августында гаиләдә 4 нче бала булып дәньяга килгән. Бүгенге көндә улы Исрафил гаиләсендә Байлар Сабасы бистәсендә яши.

Әминә Хаҗи кызы бик яшьли ятим кала. Әнисе Фатыйма үлгәннән соң 45 көн үтүгә, әтисе Хаҗи да авырып үлеп китә. Сугыш чоры авырлыклары белән бергә аңа ятимлек ачысын да татырга туры килә.

1928 елда туган апасы Җәмилә фермада эшли, 1926 елгы абыйсы армия хезмәтенә алына.

Ул башлангыч сыйныфка укырга барганын бераз хәтерли, ләкин аңа укуын дәвам итәргә насыйп булмый.

1926 нчы елгы абыйсы Мәхәммәт армия хемәтеннән сугышка алынып, 7 елдан соң исән-сау әйләнеп кайта.

1929 елгы абыйсы ФЗӨга укырга алынган җиреннән хәбәрсез югала.

Аннан 2 генә яшькә олы апасы Җәмилә аның иптәше, таянычы була.

Әминә әби колхозда кырчылыкта эшли, урак ура, чүп утый. Сугыш тәмамланганын, урамда кешеләр шатланышып, баш киемнәрен һавага чөеп куанганнарын хәтерли.

Сугыш тәмамлангач, ул фермага бозаулар карарга эшкә төшә, бераздан сыер савучы булып күчерелә.

Япь - яшь кызларга бик авыр хезмәтләр башкарырга туры килә: кыш көне бәкедән сыерларга эчерергә су ташу, азык хәзерләү, сыерларны исән - сау бозаулату, фермадан соң урып - җыю вакытында Шәмәрдәнгә капчык тәяргә менүләр дә алар җилкәсенә төшә.



1956 елда Байлар Сабасы егете Равил Шакиров белән тормыш корып җибәрәләр.



Бер-бер артлы 4 балалары туганнан соң, ул колхоз конторасында җыештыручы булып эшли башлый.

Равил бабам колхозда алдынгы тракторчы була. Аның әтисе Исмәгыйль сугышта үлеп кала. Әнисе Мәрьям әби аларга бик нык ярдәм итә. “Бик җитез, эшчән иде” - дип искә ала әби кайнанасын.

1991нче елда Әминә әби лаеклы ялга китә. 1995нче елда әбиемнең тормыш иптәше Равил бабай үлеп китә. Бүгенге көндә 85 нче яшен тутыручы Әминә әбием илгә тынычлык , муллык теләп, безнең шатлыкларга куанып, бәхетле гомер кичерә. “Без күргәннәрне беркемгә дә күрергә язмасын, бәхетегез булсын, балалар”, - ди ул безгә.

**Бу мәгълүматны Сәләтле балалар мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы Шакирова Ләлә Исрафил кызы әзерләде, 2016 нчы ел.**

# Хужина Мәмдуха Әлмөхәммәт кызы



1925 елның 28 февралендә Байлар Сабасында урта хәлле крестьян гаиләсендә туган. 1942 елны Саба урта мәктәбенең сигезенче сыйныфын тәмамлаганнан соң (I–II сыйныфларда терәк мәктәптә укыган), район халык судында секретарь булып эшли башлый. Сугыш еллары бик авыр була. Күпме солдат сугыш кырында башын салып кала.

Мәмдуха апа 1945 – 1953 елларда комсомол райкомында учет бүлеге мөдире, ә 1954 елның 20 январеннан 1980 елның августына кадәр район Мәгариф бүлегендә экономист булып эшләгән. Урта белемне 1967 елда кичке сыйныфларда укып алган.

Лаеклы ялга чыкканнан соң да озак еллар (1992 елның февраленә кадәр ) мәгариф хезмәткәрләре профсоюзының район комитетында казначей вазыйфасын үти. Мәгариф учреждениеләренең эшчәнлеген экономик яктан нигезләү, финанслау, планлаштыру, тарификация үткәрү мәсьәләләрендә мәктәп директорлары, балалар бакчалары мөдирләре белән аңлашып, закон кысаларында аларга мөмкин кадәр ярдәм итүләре, төгәллеге, тыйнаклыгы өчен аны хөрмәтләделәр.

Саба мәктәбе, район мәгарифе тарихына кагылышлы мәсьәләләрне ачыклауда ул һәрвакыт теләп катнаша, истәлекләре белән уртаклаша.



„50 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941—1945 гг."

Б № 1444241

Хузина
Мамдуха
Альмиевна


Награжден(а) юбилейной медалью „50 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941—1945 гг."


Указ от 22 марта 95 г.




Президент Республики Татарстан Указ от 08.06.98
Наименование государственного органа, принявшего решение о присвоении звания ветерана
УДОСТОВЕРЕНИЕ
Серия П № 342489
Хузина
Мамдуха
Альмухаметовна
Хузина
М.П.
Предъявитель настоящего удостоверения имеет права и льготы, предоставляемые на условиях и в порядке, установленных статьями 22 и 23 Федерального закона "О ветеранах"
Ветеран труда
полное наименование соответствующей категории ветеранов
УДОСТОВЕРЕНИЕ БЕССРОЧНОЕ ДЕЙСТВИТЕЛЬНО НА ВСЕЙ ТЕРРИТОРИИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
Дата выдачи "25" июня 1998 г.
М.П.




Мәмдуха Хуҗина намуслы, тырыш хезмәте өчен “За добросовестный труд в годы Великой Отечественной войны 1941-1945 гг”, “Ветеран труда” һәм юбилей медальләре , Мәгариф органнарының Мактау грамоталары белән бүләкләнгән.


„ПОБЕДИТЕЛЬ СОЦИАЛИСТИЧЕСКОГО СОРЕВНОВАНИЯ 1975 ГОДА"
Знак учрежден Центральным Комитетом КПСС, Советом Министров СССР, ВЦСПС и ЦК ВЛКСМ
УДОСТОВЕРЕНИЕ
Хузина
Мамдуха
Альмиевна
награждена знаком
„ПОБЕДИТЕЛЬ СОЦИАЛИСТИЧЕСКОГО СОРЕВНОВАНИЯ 1975 ГОДА"
Постановление № 231
от 8 апреля 1976 г.
„20" апреля 1976 г.
(подпись) (подпись)


„ТРИДЦАТЬ ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941—1945 гг."
УЧАСТНИКУ ТРУДОВОГО ФРОНТА
УДОСТОВЕРЕНИЕ
Хузина
Мамдуха
Альмухаметовна
В СООТВЕТСТВИИ С УКАЗОМ ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР от 25 апреля 1975 года НАГРАЖДЕН ЮБИЛЕЙНОЙ МЕДАЛЬЮ
„ТРИДЦАТЬ ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941—1945 гг."
От имени Президиума Верховного Совета СССР медаль вручена
26 декабря 1975 года
Председатель Сабинского исполкома
М.П.

**Бу мәгълүмат Хәйдәр Фасхиевичтан алынды.**

# Сафина Бибисәрвәр Сафиновна

Сафина Бибисәрвәр Сафиновна (кыз фамилиясе Сафина) 1932 елның 15 июнендә Байлар Сабасы районының Тимершык авылында туып үскән. Гаиләдә 4 бала булалар, Бибисәрвәр Сафиновна иң кечкенәсе була.

1940 елны Тимершык авылыннан 11 гаилә Бурят-Монголияга китәләр. Шулар арасында гаиләсе белән Бибисәрвәр Сафиновна да була. Яшәү шартлары анда бик начар булып чыга. 1941 елның 1 маенда, бер ел әти-әнисе Бурят-Монголиядә эшләгәннән соң, Бибисәрвәр Сафиновна әнисе һәм олы апасы, абыйсы кире үз авылларына кайтып китәләр. 1941 елның 22 июнендә сугыш башланып китә. Әтисе 1878 елгы булганга күрә аны сугышка алмыйлар, ә абыйсы китә. Тормышның ачысын да, тәчесен дә күреп үскән Бибисәрвәр Сафиновна. Өйләрдә суык, халык ач. Беренче елны хәтта бәрәңге дә утыртырга рәхсәт итмиләр. Сугыш чорында авылда кемнәр калган барысы да нинди эш бар шуны эшләгән. Олыраклар колхозда иген үстергән, урган -суккан, кемнәрдер сугыш кырындагы солдатларны җылы оекбашлар, киемнәр белән тәэмин итеп торган, хәтта кечкенә мәктәп балалары да тырышып бәрәңге, борчак чүпләгәннәр. 1942 елның декабрендә абыйсы сугыштан кулы яраланып кайта. Өйләнә, тормыш иптәше белән дүрт бала тәрбияләп үстерәләр. Ул елларның авырлыгы турында язып кына бетерерлек түгел. Ләкин алар бер дә бирешмәгән, барлык авырлыкларны җиңеп алга, бөек җиңүгә омтылганнар. Ватаныбыз өчен үзен жәлләми, кән - тән ачлыкта да, суыкта да тырышып хезмәт куя. Хезмәтләре өчен Бибисәрвәр Сафиновна 6 медаль белән бүләкләнә.Сугыштан соң да Тимершык авылында яшәгән, эшләгән Бибисәрвәр Сафиновна. Бары 60-нчы еллардан соң гына Түбән Кама шәһәренә күченеп китә. Анда заводка, вредный цехка эшкә керә. Озак еллар яши Түбән Кама шәһәрендә яши.



Хәзерге көндә ул Байлар Сабасы бистәсендә яши. Абыйсының кызлары - уллары аңа гел ярдәм итеп торалар.

# Усманова (Галимова) Флюра Кәрәм кызы



Усманова Флюра Кәрәм кызы (кыз фамилиясе Галимова) 1931 елның 16 апрелендә Башкортстанның Гафури районы Котлы Гуҗа авылында урта хәлле гаиләдә дөньяга килә. Бала вакытта ук Флюра апаның әнисе вафат булып, ул ятим кала.

Ачы еллар килеп җитүгә, ашау яклары бик авырдан була, икмәк бик аз булгач, яз чыгу белән үлән кайнатып эчә идек,- ди ул.

Тылда калган 14-15 яшьлек кыз балага сугышның бөтен авырлыгын күрергә туры килә. Ул урман чистарту, зур-зур агачлар кисү эшләрен башкара. Монысы ир-ат эше дип, һич тә санлашып тормый, тормышта да, хезмәттә дә бар авырлыкны җилкәсенә салып гомер итә.

Инде сугыш бетеп, көннәр арулана башлагач та, Флюра апага авыр эшләр башкарырга туры килә: башта ул штукатур-маляр вазифасын үти, аннан соңгы елларда пекарняда зур чаннарда камыр изә (бу эштә аягы пешеп җәрәхәтләнә), йортлар төзү белән шөгыльләнә.

1954 елда Баулы районы егетенә кияүгә чыга. Алар бергәләп 3 кызны үстерәләр, укыталар, олы тормышка аяк бастыралар. Күп тә үтми, ачы язмыш аны яңадан сыный, 54 яшьлек ире үлеп китә.

Флюра Усманова үзенең эш нәтиҗәләре, тырышлыгы, батырлыгы өчен 3 медальга лаек була.

Гомере буе хезмәттә булган Флюра апа лаеклы ялга чыга. Авыр тормыш үзен сәламәтлектә дә чагылдыра, аңа инсульт һәм микроинсульт кичерергә туры килә. Бүгенге көндә ул олы кызы һәм кияве тәрбиясендә Сабада яши. Бәләкәй кызы Ташкентта, уртанчысы Башкириядa гомер итәләр.

Төп йортның утын сүндермичә, нигезен таркатмыйча тыныч кына гомер итүче батыр йөрәкле Флюра апабызга сәламәтлек, озын гомер, бәхетле картлык теләп каласы килә. Бүгенге тыныч тормышыбызны яулап алуда күрсәткән батырлыкларыгыз алдында баш иябез, рәхмәт әйтәбез!

**Бу мәгълүматны Сәләтле балалар мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы Газизова Гөлнәзирә Илгиз кызы әзерләде, 2016 нчы ел.**

# Кыяметдинова Фатыйма Кыяметдин кызы



Кыяметдинова Фатыйма Кыяметдин кызы 1928 елның 12 сентябрендә Саба районының Сабай авылында дөньяга килә.



Аның анасы Фәхриҗамал һәм атасы Кыяметдин алты бала алып кайталар, ләкин авыр тормыш, авыру аркасында 3 балалары яшьли бер-бер артлы үлеп китә.

Фатыйма апа Шыңар авылында 5нче сыйныфка кадәр укый, 6нчы сыйныфны укый алмый, ачы сугыш башланган дигән хәбәр килә. Ир-атларны сугышка ала башлыйлар. Аның бертуган Мәхмүт абыйсын беренчеләрдән булып алалар. Әтисе сугышта катнашмый, чөнки яше узган була.

Ул кечкенәдән эшкә үҗәт, һәр нәрсәгә оста, чиргә дә чыдам булып үсә. Сугышка кадәр авылда эшли. Явыз сугыш аяк басуга, барлык авырлыкларга карамастан, үзеннән зурлар белән иңгә-иң куеп колхоз эшенә йөри: иген чәчә, суга, ура да.

Колхозны алып бару бик кыен була, 13 яшьлек кыз авыр тыл хезмәтен үз җилкәсендә татып карый. Бу елларда ул япь-яшь кенә кыз булса да, ир-ат көченә генә бирешерлек эшләр башкарырга туры килә аңа.

Елның нинди вакыты булуына карамастан, көне-төне урман кисү, авыр-авыр капчыклар бушату, ат җигеп басу сукалаулар, ачлы-туклы килеш колхоз эшендә бил бөгүләр – барысы да үтә аның башыннан. Ашарга ризык җитми, арыш-бодайның һәр бөртеге бик кадерле була. Шуңа сәбәпле, ашлыкларны аз бирәләр, бөтен үстергән ашлыкның күп өлеше хөкүмәткә, фронтка озатылып бара. Фатыйма апа фронтны азык-төлек белән тәэмин итүдә катнаша.

Мәхмүт абыйсы сугыштан аягы җәрәхәтләнеп кире авылга кайта.

Сугыш еллары узып, күпмедер вакыт үткәч, Фатыйма апа кияүгә чыга, тормыш кора. Ләкин ул тормыш иптәше белән язылышмый, кыз фамилиясен үзгәртми. Озакламый бу гаиләгә Ходай малай бүләк итә.

Сугыштан соңгы елларда, Фатыйма апа пекарняда пешерүче булып эшли.



1983 елны лаеклы ялга чыга. Инде 1996 елны Сабадагы квартирага күченә һәм хәзерге көндә дә шунда гомер итә.



Фатыйма апа әйтеп, санап бетермәслек тырышлыгы, батырлыгы, җитезлеге өчен 5 медальга лаек була.














*Хәзерге урта һәм яшь буын якты дөньяда яшәве белән сугыш чоры каһарманнарына һәм ул елларның авыр йөген җигелеп тарткан ил кызларына бурычлы.*

Хөрмәтле Фатыйма апа, ихлас күңел белән ихтирам белдереп, Сезне зурлыйбыз. Чөнки Сез яшь буынның бәхетле яшәве өчен яшьлегегезне, сәламәтлегегезне кызганмагансыз. Эшләгән эшегез, тырышлыгыгыз үзегезгә меңе белән кайтсын иде. Без Сезнең белән горурланабыз һәм Сезнең батырлыгыгызга баш иябез. Сез кичергән авырлыклар бер вакытта да кабатланмасын. Илебез тыныч, күгебез аяз булсын иде. Туган җирнең кадерле, һәркемгә якын икәнен, аны сакларга кирәклеген төшендердегез. Сезгә Җиңү бәйрәмен сәламәтлек, күңел тынычлыгы белән каршыларга язсын. Сез моңа бик лаеклы! Мул, имин тормышта бәхетле тыныч гомер итүегезне телибез.

**Бу мәгълүматны Сәләтле балалар мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы Газизова Гөлнәзирә Илгиз кызы әзерләде, 2016 нчы ел.**

# Миннеханова Нурлыбикә Миннехан кызы



1928 елның 6 гыйнварында Саба районы Тимершык авылында 7 балалы гаиләдә 2нче бала булып дөньяга килә. 4 ел авыл мәктәбендә белем алгач, колхозда эшли башлый.

Сугыш башланганда Нурлыбикә апа 13 яшьлек үсмер кыз гына була әле. Әмма бала булуына да карамастан, бик күпне күрергә туры килә аңа. Бөтен авыр эшне үз җилкәсендә башкара ул. Яфрак суы эчеп, ачлы-туклы йөрүләрне бүген дә уфтанып искә ала. Әтисе Миннехан абыйга 2 сугышта катнашырга туры килә. Укый-яза белмәгәнгә, хатлары килми. Икенче Бөтендөнья сугышыннан яраланып булса да, исән килеш өенә кайтырга насыйп була аңа. Авылда агроном хезмәтен башкара әле ул.

1945 елда, сугыш беткәч, Нурлыбикә апа Сабага килә. Үзенә тиң яр очрамый аңа, шунлыктан тормышка чыкмый кала. 44 ел буе Район социаль тәэминат бүлегендә медицина хехмәткәре вазифасын башкарып, лаеклы ялга чыга. Шуннан соң тормыш итәргә дип, үзенең туган авылы Тимершыкка кайтып китә.

Соңгы 2 елда Нурлыбикә апа Байлар Сабасының Закир Йосыпов урамында урнашкан 5 йортның 22нче фатирында ялгыз гына гомер кичерә.



Дорогой (ая)

Миннеханова Нурлыбика Миннехановна!

Примите мои самые искренние и теплые поздравления со знаменательным юбилеем – 70-ой годовщиной Победы в Великой Отечественной войне!


В летописи нашей Родины есть исторические события, которые никогда не померкнут и будут вечно жить в благодарной памяти будущих поколений. Этот день стал днем чести и славы наших отцов и дедов, символом национальной гордости и безграничной благодарности, глубокой скорби и вечной памяти. В этот светлый праздник мы с благодарностью вспоминаем подвиг сыновей и дочерей Татарстана, тех, кто своей жизнью заплатил за освобождение нашей земли от фашизма. Отвага, доблесть, стойкость и самоотверженность, проявленные Вами на фронте и в тылу, не забудутся никогда.

Низкий Вам поклон и глубочайшее признание за Великую Победу, за боевой и трудовой подвиг во имя Родины и будущих поколений! Искренне желаю Вам, Вашим родным и близким доброго здоровья, долголетия, душевного тепла, бодрости, счастья и благополучия!

С глубоким уважением, Р.Н. Минниханов

# Гомәрова Зөлкамал Заһидулла кызы





Зөлкамал Заһидулла кызы 1931 елның 23 августында Саба районы Сатыш авылында туган. Әнисе белән генә яшәгән кызга башлангыч белем алырга насыйп булмый. Гаиләдә бердәнбер бала булгач, әнисе фермага эшкә барганда ялгызын өйдә калдыра торган булган.“Әнинең мине укытырга мөмкинчелеге юк иде. Иртән эшкә китеп, төнлә генә кайткач, мин өйдәге эшләрне барлап, аның кайтканын көтә идем. Аның үз туганнары да төрле якларга таралышып беткән иде”, - дип искә ала Зөлкамал апа. Бераз ныгыгач, аның эшкә керәсе килә, әмма кечкенәрәк булуын искәртеп, алырга теләүчеләр булмый. Әнисе укырга кирәклеген искәртеп торса да, кыз теләгенә ирешә: үзләренең авылында урнашкан ательега эшкә керә. Сугыш башланганда ул шунда мехтан әйберләр теккән, юрган сырган. Авылларындагы тегү цехы ябылгач, Зөлкамал апа Шәмәрдәндә 2 ел буена шул ук хезмәтен дәвам итә.



Сугыш беткәннән соң, Байлар Сабасына күчәргә туры килә аңа.Зөлкамал апа монда да үз хезмәтенә тугры калып, тегү цехында эшли башлый. Хәзерге гомуми мунча урынында урнашкан бинада юрган сыра һәм шуннан лаеклы ялга да чыга.

Тормыш иптәше Әсхәт абый белән корган тормышлары матур гына дәвам итә. Әмма балалар сөяргә генә насыйп булмый аларга. Бүгенге көндә Зөлкамал апаның тормыш иптәше вафат инде.





Зөлкамал Заһидулла кызы Байлар Сабасының Закир Йосыпов урамында урнашкан 39 йортта ялгызы гына гомер кичерә.

# Вәлиева (Габдрахманова) Нажия Габдрахман кызы



Нажия Габдрахман кызы 1927 елның 19 декабрендә Саба районы (хәзерге Теләче районы) Орымширмә авылында колхозчы гаиләсендә туа. Башлангыч белемне авыл мәктәбендә алгач, колхозда эшли башлый. Бала-чагага чүп утарга туры килә. Сугыш башланган көнне ул әле бүген дә хәтерли. “Арыш урган вакыт иде. Иртә белән мин тәрәзәгә карадым һәм шунда хатын-кызларның урам уртасында җыелышып кызу-кызу нидер сөйләшкәннәрен күреп алдым. Алар арасында минем әни дә бар иде”, - дип искә ала Нажия апа. Сугыш башлангач, апасы Казанга китеп тоз заводында эшли башлый. Гаиләдә энесе белән бергә әти-әни янында көн күрә башлыйлар. 15-16 яшьләрендә авыл халкы белән бергә урман кисәргә йөри. Ул вакыттагы авыр тормышны искә төшергәндә күзләре яшь белән каплана Нажия апаның. Авыл Советы ярдәме белән 1 ел тракторга укыгач, 3 ел шунда эшли. Әтиләре сугышка китүчеләр исемлегендә учетта тора, балалар бәхетеннәнме, аның чираты җиткәндә сугыш тәмамлана.






Сугыш бетеп, илдә тынычлык урнашкач, 1954 елның 29 декабрендә Саба егете Шамил абый белән Нәҗия апа тормыш корып матур гына яши башлыйлар. Башта Сатыш авылында гомер итәләр. Соңрак Байлар Сабасына күченәләр. Алар 3 балага гомер бүләк итәләр. Иренең әтисенә сугышта катнашырга туры килә. Аңа Кизнир хәрби частендә хезмәт итеп, илгә исән-сау кайтырга насыйп була. Килен белән бергә алар 29 ел тату гомер итәләр. Нәҗия апа озак еллар Район мәгариф бүлеге бинасын чисталык белән тәэмин итеп тора. Шамил абый исә 27 ел янгын сүндерүче булып эшләп, 1993 елда вафат була.












Бүгенге көндә Нәҗия апа Байлар Сабасының Тукай урамы 104 нче йортта үзе генә гомер итә. Казанда яшәүче кызы Наилә, Сабадагы улы Камил белән кызы Мәдинә дә аны һәрвакыт кайгыртып, хәлен белеп яшиләр.

## Фатыйхова Сажидә Исмәгыйль кызы

Сажидә  Исмәгыйль кызы 1931 елның 2нче гыйнварында Саба районы, Байлар Сабасы авылында хәзерге вакытта гомер кичерә торган йортта дөньяга килгән. Сугыш башланганда  ул бик яшь булуга да карамастан, фермада күп төрле эшләрдә булышкан, ә сугыш тәмамлангач,  тракторда эшләгән, шулай ук инкубатор,  ашханәдә дә хезмәт куярга туры килгән Сажидә апага. Сугыш елларындагы авырлыкларны сүз белән генә аңлатып булмый икәнен аңлыйбыз.1968 елдан Сажидә Исмәгыйль кызы пенсиядә. Бүгенге көндә ул улы Заһидуллин  Илдар Мәсгуть улы белән гомер кичерә. Аның гаиләсеннән абыйсы Фатыйхов Хөсәен Исмәгыйль улы сугышта катнашкан һәм шунда үлеп калган, Сажидә Исмәгыйль кызы сөйләвенә караганда, абыйсының кабере Смоленск өлкәсе Дзержинск районында саклана.

## Нургалеева (Хафизова) Халисә Якуп кызы

Халисә Якуп кызы 1929 елның 10 июнендә Теневи авылында туган. Сугыш чорында Йосыф-Алан умартачылыгында эшләгән. Бала чакта урман кискән. Халисә Якуп кызы ферма мөдире булып та, төрле эшләрдә дә  хезмәт куйган. 1972 елдан алар аиләсе белән Сабага күчеп килгәннәр. Ул “Киносеть” оешмасында методист булып эшләгән. Гаиләләреннән сугышта катнашкан ватанпәрвәрләр арасында Тимербай Якуп улы, кайнатасы Нургали, иренең абыйсы Әхмәт исемле кешеләр дә бар.

Бүгенге көндә улы  Нургалеев Илшат Хашим улы һәм аның  тормыш иптәше белән ике сабый үстерәләр.

# Хаҗиева (Рафикова) Минтаһирә Габдрахман кызы



Минтаһирә Габдрахман кызы 1932 елның 1 сентябрендә Саба районы Урта Саба авылында дөньяга килә. Иң күңелен тырнаганы- Бөек Ватан сугышы чорындагы ачлык һәм хәерчелек. Ул вакытта Шәмәрдәнгә атлар белән икмәк менгерә торган булганнар, шунда эшләп, бер телем икмәк белән түләгәннәр. 2 сәгать йокы гына тия торан булган төннәрен. “Бик авыр заманнар булды”-дип көрсенеп сөйли Минтаһирә Габдрахман кызы. Сугыш тәмамлангач, 1949 елдан ул Урта Саба кибетендә эшли ул. 1951-1952 елларда Тәтештә бер еллык курсларда укып кайткач, агроном булып Нырты ягы авылларында хезмәт куйган. 1953 елда Сабага кияүгә чыга.

Сугышта аның гаиләсеннән әтисе һәм тормыш иптәше катнашалар. Әтисе Рафиков Габдрахман Украинадан яраланып кайткач, аяклары рәтләп йөрмәүгә дә карамастан, Шашлангер дигән куркыныч җиргә эшкә җибәрәләр. Ачлыкка тилмереп, көне буе эшләп, кар өстендә йоклый торган булганнар, кайткач озак тормый күзләрен мәңгегә йома Габдрахман абый.

Сугыштан соң райпода сатучы булып та, завсклад булып та эшләргә туры килә Минтаһирә Габдрахман кызына. Лаеклы ялга ипи кибетендә эшләгән чагында чыга. Бүгенге көндә берүзе гомер кичерә, 4 кызы бар, икесе Мәскәүдә, икесе Казанда яши.



# Гарипова Фатима Гарип кызы



Фатима Гарип кызы 1931 елның 26 апрелендә Саба районы, Байлар Сабасы авылында туган, шушы ук йортта бүгенге көндә дә энесе Сәгыйть абый белән гомер итә. Тыл ветераны Фатыйма апа тылда колхозда төрле эшләрдә хезмәт куйган. Сугыштан соңгы елларда 1948-1987 елларда фермада эшләгән, сөт тә җыйган, амбарда да тырышкан. Әбинең күңеле сугыш вакытын искә алу белән тула, анда күргән авырлыкларны, ул заманнарны Ходай беркемгә дә бирмәсен иде дигән изге теләктә калды Фатима Гарип кызы.





# Муллахмәтова Нурзидә Шайдулла кызы



Нурзидә Шайдулла кызы Теләче районы, Максабаш авылында 1931 елның 28 январь көнендә туган.Тылда ат белән ашлык суктырганда ат куган, урак урган. Сугыштан соң Мамадыш районында урман кискән, колхоз кушуы буенча, 1953 нче елда торфка барып кайткан. Шул ук елны Сабага эшкә килгән, бәрәңге киптерә торган заводта бәрәңге әрчегән. Нурзидә әби 30 ел гомерен хәзерге “Шатлык” балалар бакчасында ярдәмче тәрбияче вазыйфасын башкаруга багышлаган.

1965 нче елдан алып, ул лаеклы ялда. Бүгенге көндә улы тәрбиясендә яши.



# Маннанова Асия Шафыйгулловна



Асия Шафыйгулла кызы 1927елның 25 августында Саба районы Урта Нырты авылында дөньяга килә.Әти-әнисе колхозда эшлиләр. 1934 елда гаиләләре белән Лесхоз авылына күченеп китәләр. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул Арча педагогия училищесына укырга керә.Укытучы дипломын алу белән туган ягы Саба районына эшкә кайта. Беренче хезмәт еллары Килдебәк урта мәктәбендә башлана, анда ул 2 ел эшли. Маннанов Габдлебар Маннан улы белән тормыш башлап җибәрәләр.Асия Шафигулла кызы эшен Икшермә урта мәктәбендә дәвам итә.

Маннанов Габдлебар Маннан улы – Бөек Ватан сугышы ветераны. Соңгы көннәрендә ул ул район газетасында баш мөхәррир ярдәмчесе вазыйфасын башкара.1982 елда вафат була.

Асия Шафыйгулла кызының педагогик стажы 43 ел. Ул бик күп еллар Саба урта белем бирү мәктәбендә эшли.Эшендә яхшы күрсәткечләре өчен мактау грамоталары белән бүләкләнә.









Асия Шафыйгулла кызы –тыл ветераны. Сугыш елларында госпитальда эшләргә туры килә аңа, яраланган солдатларны карый, аларның өйләренә хатлар җибәрергә булыша.

Сугыш елларында шулай ук колхозда, фермада да эшләргә туры килә аңа.







# Степанова (Хафыйзова) Гөльфагыйлә Хамиз кызы



Гөльфагыйлә Хамиз кызы 1930 елда Теләче районы Сәвруш авылында дөньяга килә. Сугыш башланганда аңа 11 яшь була. Гаиләдә 6 бала тәрбияләнәләр, 1 малай һәм 5 кыз. Иң олы бала булгач, күбесенчә эш аның җилкәсенә төшә: вагон бушату, урман кисү. “Көне буена 2 бәрәңге ашап эшли идек. Ипи булган көнне,әни үзебез белән биреп чыгарды. Үзе көне буе кырда, күзләре бик каты шешә иде, кайбер  көнне арбага салып алып кайтып, күрше апасы төне буе әрекмән яфрагы куеп саклап чыга иде”- дип искә ала Гөльфагыйлә Хамиз кызы.

Сугыштан соңгы елларда колхозда эшли. 24 яшендә кияүгә чыга.Тормыш иптәше белән Мамадыш районына күченеп китәләр.8 ел гомер иткәннән соң Саба районына күченеп кайталар. Гөльфагыйлә Хамиз кызы  35 ел гомерен “Шатлык” балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе вазыйфасын башкаруга багышлый. Ике малай үстерә. Олы улы инде вафат,хәзергесе көндә ул кече улы гаиләсендә гомер кичерә. 4 оныгы, 6 оныкчыгы - сөенече бар.





# Баһавиева Мөнәвәрә Шәкүр кызы





Баһавиева Мөнәвәрә Шәкүр кызы Байлар Сабасында 1930 елның 13 декабрендә туган. 1952нче елда фермага сыер савучы булып эшкә керә. 38 ел фермада эшли һәм шушы вакытта 4 елга депутат булып сайлана. Алдынгы хезмәткәр була. Шул уңайдан 1956 нчы елда  Мәскәү шәһәренә алдынгылар күргәзмесенә чакыру белән бүләкләнә. Мөнәвәрә апаның  истәлекләре: ул вакытларда урман кисү, вагон төяү, урак уру, көлтәләр бәйләү шикелле эштән бушап та тормадык; ачлыкны күрдек, черек бәрәңге, алабута ашап үстек, - дип искә ала ул (күзләрендә яшь).



Мөнәвәрә апаның бик күп кенә медальләре, орденнары бар ( 5 бала өчен медаль, Ленинның 100 еллыгына һ.б.).

Мөнәвәрә апа  5 бала тәрбияләп үстергән: Мөнәвир, Марат, Сәгыйдә, Сиринә, Айрат. Хәзерге вакытта 3 баласы исән, 8 оныгы бар, 1 оныкчыгы бар.

Шушы көннәрдә Мөнәвәрә апа Лениногорский шәһәрендә кызы Сиринә яныннан кунак булып кайткан. Шуннан соң Казанда оныгында тәрбиядә булып кире Сабага әйләнеп кайткан.

-Бүгенге көндә мин бик бәхетле, Ходаема рәхмәтле, -дип сөенә Мөнәвәрә апа.

# Корбанов Рәеф Корбан улы



Корбанов Рәеф Корбанович 1931 нче елда Байлар Сабасында дөньяга килә. 1946нчы елда Саба урта мәктәбендә 7 класс белем ала. Сугыш елларында күп еллар торфта, урман кисүдэ эшли. Әниләре белән берлектә ат җигеп басу - кырларда эшлиләр.

1951 нче елдан 1955нче елга кадәр Владивосток шәһәрендә Тын океан флотында диңгез гаскәрендә хезмәт иткән. Матрос дәрәҗәсендә телефончы вазифасында эшли.

Рәеф Корбанович бик оста гармунчы була. Күп кенә кичәләргә, концертларга аны бик хөрмәт итеп чакыралар.

Озак авырганнан соң Рәеф Корбанович 2015 елның җәендә вафат була.



# Гасыймова Миннехода Зыятдин кызы



Гасыймова Миннехода Зиатдин кызы 1925 елнын 29 мартында Саба районы Мингәр авылында дөньяга килэ.Әтисе Зыятдин, әнисе Гөлзәйнәп исемле гаиләдә икенче бала булып туа. Разия, Миннехода, Гаязетдин, Рафил, Марзия, Раббани, Рафыйк- барысы 7 бала. Бүгенгесе көндэ икесе вафат. Әтиле - әниле тигез гаиләдә яши. Миңгәр авылында канцеляриеда колхоз хисапчысы булып хезмәт куя.








Сугыш елларында күп еллар торфта, урман кисүдә эшли. Әниләре белән берлектә ат җигеп басу-кырларда эшлиләр. 1951 елда Пушкин колхозында (Мингәр авылы) счетовод булып эшли.

1957 елда 32 яшендә Сабага килэ. 4 бала белән ятим калган Мөхәммәтвагыйз белән 1959 елда язылышалар.

1959 елда Саба сельпосында зав.ларек булып эшли. 1961 елда Саба май заводында учетчица, 1963 елда- загоскотта хисапчы, 1964 елда –Абди совхозында хисапчы, 1966 елда Саба киносетендэ хисапчы, декабрьдә комиссион кибеттә эшли, 1974 елда Продмаг №1 сатучы, 1976 елда лаеклы ялга китә.

# Галимова Латыйфа Фәрхулла кызы



Галимова Латыйфа Фархулла кызы 1929 елның 16 февралендә Саба районы Сабабаш авылында дөньяга килә. 1941 елда әтисе һәм өч абыйсын сугышка алып китәләр. Сугыш  елларында ул урман кисүдә катнаша. Ачка үлмәс өчен яфрак, черек бәрәңге җыя.

Әнисе авыру булу сәбәпле, әнисен тәрбияли.

Латыйфа Фархулла кызы бик күп медальләргә ия.



Бүгенгесе көндә Латыйфа апа балалары белән яши. Аңа 87 яшь.

# Гәрәева Бану Вәлиәхмәт кызы





Гәрәева Бану Вәлиәхмәт кызы 1928 елның 29 маенда Татарстан республикасының Саба районы Байлар Сабасы авылында ярлы крестьян Вәлиәхмәт һәм Шәмсекамәр гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга  килгән. Олы апасы Фәрдәнә (1920 елгы), абыйлары Нуриәхмәт (1923 елгы), Мулләхмәт (1929елгы), Сәитәхмәт(1926 елгы), энесе Нурмөхәммәт (1929 елгы) булалар. Кызганычка каршы, энесе 3 яшьтә фаҗигале рәвештә вафат була. Әтиләре 36 яшендә үпкәсе кабарудан үлеп китә.Гаиләнең матди хәле бик авыр була. Олы балалар, укуларын калдырып, эшләргә мәҗбүр булалар. Озак та үтми, Бөек Ватан сугышы башлана. Ике абыйсы да сугышка алына.  Нуриәхмәт Сталинград өчен барган сугышларда хәбәрсез югала.

Җидееллык мәктәпне тәмамлаган Бану инкассатор булып эшли башлый. Һәркөн кибетләрдән җыелган акчаларны, Байлар Сабасыннан 30км ераклыкта урнашкан, Теләчедәге банкка илтеп тапшыра торган була. Янында ат тотучы һәм мылтык, мөгаен ул аннан  файдалана да белмәгәндер әле. Ярый әле ул заманада бу тирәләрдә бандитлар булмаган, ә авыл халкы гадел һәм тәртипле булган.

Сугыштан соң Бану сатучы булып эшли. 1952 елда Миннәхмәт Вәлиәхмәтов белән тормыш корып җибәрә. 1953 елда кызлары Илсөяр туа. Ире вафат булу сәбәпле, Бану Гәрәев Тимербай Җиһангир улына (1934 елгы) кияүгә чыга. Аларның 1962 елда кызлары Әлфия, 1965 елда кызлары Люция туа.

.

Коммуналь хезмәт күрсәтү идарәсендә 10 ел бухгалтер - учетчы хезмәтен башкара . Ә калган гомерен, пенсия яшенә җиткәнче, Байлар Сабасы бистәсендәге кибетләрдә сатучы булып эшли. Бѳек Ватан сугышы вакытындагы фидакарь хезмәте ѳчен “Бѳек Ватан сугышы ветераны” медале белән бүләкләнә.

Олы кызы Илсөяр, Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетын тәмамлап, (инспектор по делам несовершеннолетних) булып эшләп, МВД подполковнигы дәрәҗәсендә лаеклы ялга чыга. (Бүгенге көндә гаиләсе белән Байлар Сабасында яши.)

Кызы Ләйсән(1976ел.) Казан дәүләт финанс-экономика институтын тәмамлаган. Тормыш иптәше Маннанов Руслан белән Казан шәһәрендә яшиләр, бер кыз һәм бер ул тәрбиялиләр.

Улы Тимур (1985ел) Казан дәүләт финанс-экономика, Казан дәүләт юридик институтларын тәмамлаган. Хәзерге вакытта Екатеринбург шәһәрендә эшли.

Икенче кызы Әлфия Казан дәүләт педагогия институтының чит телләр факультетын тәмамлаган, Саба гимназиясендә инглиз теле укыта. Тормыш иптәше Әхмәтгалиев Марат Җәүдәт улы белән 3 бала үстергәннәр.

Олы кызлары Алия (1987ел) Казан дәүләт педагогия институтының чит телләр факультетын тәмамлаган. Бүгенге көндә ире Журавлѐв Денис белән Мелана исемле кыз үстерәләр.

Уллары Айрат (1988ел) Казан аграр университетының механика факультетын тәмамлаган, “Ак таш” тѳзелеш компаниясендә эшли. Ѳйләнгән, хатыны Сабирова Алина белән Радмир исемле ул үстерәләр.

Кече кызлары Алина (1995ел) Казан дәүләт педагогия институтының чит телләр факультетында укый.

Бану апаның ѳченче кызы Люция Казан дәүләт педагогия институтының чит телләр факультетын тәмамлаган. Бүгенге көндә Шәмәрдән бистәсендә “Әкият” балалар бакчасында инглиз теле укытучысы һәм психолог вазифаларын башкара. Тормыш иптәше Шакиров Каниф белән ике кыз үстерәләр.

Олы кызлары Алсу (1991ел) Казан дәүләт педагогия институтының инглиз теле һәм психология факультетын тәмамлаган. Бүгенге көндә ире Нәгыймов Делюс белән Казан шәһәрендә яшиләр, мәктәптә инглиз теле укыта.

Кече кызлары Әдилә(1994ел.) Казан химико-технология университетында укый.

Бану апа 2015 елның җәендә вафат була.

# Каримова (Хабибрахманова) Анфиса Кыям кызы



Каримова (Хабибрахманова) Анфиса Кыям кызы 1931 елның 14 апрелендә Татарстан республикасының Саба районы Байлар Сабасы авылында интеллигенция гаиләсендә туган. Әтисе, Хабибрахманов Кыяметдин Хабибрахман улы, райкомның икенче секретаре; әнисе, Хабибрахманова Хәтирә Хайрулла кызы сатучы булып эшлиләр. Гаиләдә өч бала тәрбияләнә: Анфиса, Рөстәм, Равия. (Хәзерге вакытта өчесе дә исән – саулар).

Әтисе Хабибрахман абый сугышка райкомның икенче секретаре булып эшләгәндә 1942 елның көзендә алына. Ә 1943 елда Сталинград шәһәре өчен барган сугышларда вафат була. Сталинград шәһәрендә Бөек Ватан сугышында башларын салган ватандашларыбыз истәлегенә куелган монументка аның исеме дә язылган. Әтисенең абыйсы Хабибрахманов Миннегали Хабибрахман улы фин сугышында вафат була, ә энесе Хабибрахманов Миннәхмәт Хабибрахман улы Бөек Ватан сугышында катнашып, исән-имин әйләнеп кайта.



Сугыш башланганда Анфиса Кыямовнага 10 яшь була. Сугыш вакыты аның балачак елларына туры килә. Авылның башка балалары белән җәй көннәрендә колхоз кырларына чүп утарга, башак җыярга, киндер йолкырга йөрергә туры килә. “Хезмәт көненә бирелә торгән 200 грамм ипине алырга, кырдан кайтышлый, колхаз келәтенә керүләр әле дә истә,” -дип искә ала ветеран укытучы. Алдынгы карашлы әти-әнисе аны рус сыйныфына укырга бирәләр. Ләкин 7 сыйныфта укыганда Сабада рус сыйныфы бетерелә Һәм аңа 7 сыйныфны Завод Нырты мәктәбендә тамамларга туры килә. Ә 8,9,10 сыйныфларны Саба урта мәктәбендә бер сыйныфта 5 укучы тәмамлыйлар.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң 1 ел (1948-1949ел) Саба урта мәктәбендә башлангыч сыйныфларда рус теле укыта. 1949-1950 елларда Шмит башлангыч мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы, 1950-1951 елларда Икшермә мәктәбендә , 1951-1953 елларда Сатыш мәктәбендә рус теле укытучысы булып эшли. Шул елларда Каримов Әмин абый белән тормыш корып, Сатыш авылында яшиләр. Әмин абый Сатыш авылында сельпо председателе булып эшли. 1948-1950 елларда экстерн рәвештә Казан дәүләт педагогия училищесын тәмамлый.  1954 елда гаиләләре белән Сабага күчеп кайталар һәм Анфиса Кыямовна балалар бакчасына тәрбияче булып урнаша.  Ләкин юллар аны яңадан мәктәпкә илтә. 1956 елдан алып, лаеклы ялга чыкканчы, Саба урта мәктәбендә башлангыч сыйныф укучыларына белем һәм тәрбия бирә.  Күп кенә яшь укытучыларның остазы, әти – әниләрнең хөрмәле укытучылары булып яши ул бүген дә. Анфиса Кыямовнаның тырыш хезмәте күп санлы мәктәп, район, республика мактау грамоталары белән бәяләнгән.

Анфиса апа белән Әмин абый ике кыз тәрбияләп үстерәләр. Икенче кызлары Рәйсә тормыш иптәше Шамил белән Байлар Сабасы бистәсендә яши. Гаиләдә ике бала: уллары Алмаз һәм кызлары Алия. Бүгенге көндә Анфиса Кыямовна кызы Рәйсә һәм кияве Шамил гаиләсендә тәрбияләнә. Ул бистәбезнең хөрмәле остабикәсе, Ак әбисе, авылдашларының якын киңәшчесе.

Бу мәгълүматны Сәләтле балалар мәктәбенең 3б сыйныфы укучылары әзерләде, 2016 ел

## Мәрданова Сәвия Корбан кызы

Мәрданова Сәвия Корбан кызы 1925 елнын 11 гыйнварында Байлар Сабасында дөньяга килә. Бала -чагы ачы сугыш елларына эләгә аның. Ир-атлар сугыш кырында, ә хатын-кызлар бар тормышны үз җилкәләренә алып көне-төне эштә була. Сәвия Корбан кызы да бу елларны бик яхшы хәтерли. Ул елларда урман кисүдә катнаша ул.

Бүгенге көндә кызы тәрбиясендә Байлар Сабасында гомер кичерә.

## Шәйдуллина Әльфия Сабир кызы

Шәйдуллина Әлфия Сабир кызы 1930 елның 6 февралендә Саба районы Сәрдә авылында дөняга килә. Аңа сугыш чорының бар авырлыкларын үз җилкәсендә күтәрергә туры килә: елның нинди вакыты булуына карамастан, көне-төне урман кисү, авыр-авыр капчыклар бушату, ат җигеп басу сукалаулар, ачлы-туклы килеш колхоз эшендә бил бөгүләр – барысы да үтә аның башыннан. Ашарга ризык җитми, арыш-бодайның һәр бөртеге бик кадерле була. Шуңа сәбәпле, ашлыкларны аз бирәләр, бөтен үстергән ашлыкның күп өлеше хөкүмәткә, фронтка озатылып бара. Әлфия апа фронтны азык-төлек белән тәэмин итүдә катнаша.

Сугыш чорындагы тырыш хезмәтләре өчен аның бүләкләре: “Медаль за доблестный труд” (26.05.1989 елны бирелә), “За долголетний добросовестный труд от имени Президиума Верховного Совета ССР Указом Президиума Верховного Совета Татарской АССР” (13.11. 1987 елны бирелә), 1989 елда эшендә яхшы күрсәткечләргә ирешкән өчен “Рәхмәт хаты” бирелә, Җиңүнең 55 еллыгына истәлек билгесе белән бүләкләнә.

Әлфия Сабир кызы 2015 елның 14 маенда вафат була.

# Котдусова (Валиева) Нәфисҗамал Галим кызы





Мин дә тылда эшләгән өчен бик күп мактау кәгазьләре, орден – медальлары булган ветеран белән таныштырасым килә. Ул әбием, Котдусова (Валиева) Нәфисҗамал Галим кызы. Әбием 1925нче елның 30нчы октябрендә, ямьле табигатьле, Саба районы Тимершык авылында дөньяга килгән. Балачагы сокландыргыч су буйлары, чәчәкле болыннары белән истә калса, үсмер чагы башка вакыйгаларга бай булган әбиемнең. Чөнки Тимершык урта мәктәбендә җиде класс белем алгач, аңа төрле авыр эшләрдә эшләргә туры килгән. Чөнки бу вакытларда илебездә сугыш башланган. Шул сәбәпле, авыл халкы ирләрсез калган, барлык эш хатын – кызлар һәм балалар җилкәсенә йөкләнгән. Шул чорның һәр кешесе дә хәтерләгән кебек әбием дә, газиз әнисен һәм энеләрен кочаклап, әтиләрен пар атларга утыртып алып киткәннәрен әле дә зур тәэсирлек белән искә ала.

Әтиләрен озаткач, әбием энеләрен карый, әнисенә ияреп колхоз эшенә чыга. Тик колхоз эшләрендә генә сыналмыйлар яшьләр, чөнки немец солдатларына каршы тору, илебезне саклау бурычы ирләр кулында гына булмый, ә яшүсмер кызларга да өлеш чыга. Барлык авыллардан кызлар бригадалары җыеп, төрле районнарга окоп казырга җибәрәләр. Әбием Апас районы Йомралы авылында тир түгә. Ә инде окоп казу бурычын тәмамлап кайткач колхоз эшендә ирләр ролендә, трактор йөртүчеләр җитмәү сәбәпле, шул профессияне  үз итәргә туры килә. Һәм әбием Арча районы Үрнәк һөнәр училищесында белем ала. Берничә ай эчендә трактор йөртү таныклыгына ия булып, туган авылында 1949 елга кадәр трактор иярли. Шушы вакыт эчендә сугышның төрледән – төрле хәбәрләре килеп тора.

1945 елның яз аенда  совет солдатларының җиңүе белән сугыш тәмамлана. Тик туган якларына, өзелеп көтүче гаиләләренә әйләнеп кайтучы солдатлар саны гына сөендерми. Ә шулай да кайтучылар була бит һәм әбиемнең дә әтисе, бер кулы яраланган килеш, туган ягына кайта. Әбиемнәрнең гаиләсе түгәрәкләнә, сөенечләре арта, гаиләләре ишәя.

Әбием 1949 елның, шомыртлар чәчәк атып, барлык дөньяны хуш ис белән баеткан, май аенда Саба районы Көек авылына яшь килен булып килә. Алар бабаем – сугыш ветераны, Котдусов Хөснулла Котдус улы белән бик матур, күркәм гаилә коралар. Яшь гаилә парлашып башта Иштуганда урнашкан урман чыгару, вагоннарга агач төяү белән шөгыльләнә. Ә аннан, гаиләләре ишәя төшкәч, колхоз эшенә керешәләр. Әбием колхозда төрле эштә эшләүче була. Бабаем бик оста куллы төзүче була, хәтта сугыштан соң да ике ел Сталинградны төзекләндерүдә хезмәт итә, шуңа авылларының төзелеш биналарында эшли. Хәзер дә берничә биналы терлек фермасында һәм авылның йөзек кашы булган мәчет биналарында аның кул җылысы бөркелеп тора.

Әбием белән бабаем дөньяда биш балага гомер бүләк итәләр. Шуларның өчесе бүгенге көндә үз гаиләләре белән, оныкларына үрнәк булып яшиләр. Ә әбием үзе малае Котдусов Габид һәм килене Гыйльмия тәрбиясендә бик күркәм ак әби булып, кадер – хөрмәттә дөнья кичерә. Көн дә дога кылгач, бүтән беркайчан сугыш афәтләре чыкмасын, илебез күге тыныч булсын, исән – сау яшәргә язсын дигән теләкләрен кат – кат кабатлый.



**Бу мәгълүматны ветеран әбинен оныгы, Сәләтле балалар мәктәбенең химия һәм биология фәннәре укытучысы Валиәхмәтова Гөлия Габид кызы әзерләде, 2016 нчы ел.**

# Вәлиева (Зыятдинова) Хурия Зыятдин кызы



Хурия Зыятдин кызы 1926 елның 29 маенда Саба районы Тенеки авылында дөньяга килә.1941 елның маенда Саба урта мәктәбенең 8 нче сыйныфын тәмамлый. 1941 елның 2 июнендә, сугыш башланырга 20 көн кала, әнисе кинәт вафат була. Әтисен сугышка алалар.15 яшьлек кыз бала берүзе кала. Авыр булсада сыгылып төшми, илгә килгән сугыш афәтен җиңәр өчен өлкәннәр белән берләттән җиң сызганып эшли ул.Чура урманнарында урман кисә.





Сугыш беркемне дә аямый, әле бала гына булуына карамастан , ул да ил алдындагы бурычын үтәргә тиеш була.Авыр балачагы үтеп, 1945 елның октябрендә Саба госбанкында эшли башлый.1951 елда Саба МТСында учетчик-заправщик булып эшен дәвам итә.1958 елда Саба сельпосында кибетче,1958 елда Саба МТСында секретарь-машинистка,1960 елның ноябреннән 1961 елның июненә кадәр райисполкомда секретарь-машинистка,1961 елда сәүдә өлкәсендә эш юлын тәмамлый.1981 елда лаеклы ялга чыга.

1984 елда “Ветеран труда” медале, 1990 елның 27 сентябрендә сугыш ветераны һәм тыл ветераны таныклыгы белән бүләкләнә.


„50 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941—1945 гг.“

Б № 1408709

НАГРАЖДЕН(А) ЮБИЛЕЙНОЙ МЕДАЛЬЮ

„50 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941—1945 гг.“


„СОРОК ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941—1945 гг.“

УЧАСТНИКУ ТРУДОВОГО ФРОНТА

УДОСТОВЕРЕНИЕ

В СООТВЕТСТВИИ С УКАЗОМ ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР от 12 апреля 1985 года НАГРАЖДЕН ЮБИЛЕЙНОЙ МЕДАЛЬЮ

„СОРОК ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941—1945 гг.“

От имени ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР медаль вручена


„65 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941–1945 гг.“

А № 1409166

Указом Президента Российской Федерации от 4 марта 2009 г. награжден(а) юбилейной медалью

„65 ЛЕТ ПОБЕДЫ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941–1945 гг.“

От имени Президента Российской Федерации медаль вручена

# Зарипова Сәрия Габдулловна



Зарипова Сәрия Габдулловна, 1928 елның 8 нче февралендә Саба районы Байлар Сабасы авылында дөньяга килгән. 8 яшьтә мәктәпкә укырга кергән,7 нче класска кадәр белем туплаган, алга таба укытучы буласы килеп, укуын дәвам итәргә исәпләгән. Ләкин 8 нче класска керер өчен 150 сум түләргә кирәклеген белгәч, ул бу чынга ашмас хыял икәненә төшенә. Тормышлары бик авыр була аның гаиләсенең. Әниләре берүзе 4 бала үстергән, Сәрия апа сугыш башланганда аңа 12 яшь булган, колхозда төрле эшләрдә көч куйган: клубарь, чүп утаучы, тавык тизәкләре җыючы, ашлыкларга су сибүче, сыер савучы һәм башкалар... Колхозда ирләр калмагач, Сәрия апаны трактор йөртүчегә укырга җибәрмәкче булганнар, ләкин әнисе аны җибәрүгә каршы төшкән.





Аның гаиләсеннән сугышта абыйсы Әхмәтҗанов Шәрифулла Габдулла улы катнашкан. Дунай елгасын узганда, немец гаскәре өсләренә бомба ташлагач, ул шундук җан биргән. Хәбәрсез югалуы турындагы хәбәр Саба военкоматында саклана. Сугыш беткәч, Сәрия Габдулла кызы Бөгелмә шәһәрендәге сәүдә-кооперация мәктәбенә 1 еллык укуга барган. 1953 елда кияүгә чыккан, бер кыз баласы булган. Ул аны ире белән аерылышкач, берүзе генә тәрбияләп үстергән, кызы аның хыялын тормышка ашырган-укытучы булган. Кызганычка каршы, ул якты дөнья белән 55 яшендә саубуллашкан, яман чир аны гаиләсеннән 2011 елда аерган. Ләкин, Эльмира Идрисовнаның тормыш иптәше һәм улы Марат Сәрия Габдулла кызын карап-тәрбияләп торалар, чөнки тыл ветераны әбинең аяклары йөрми һәм күзләре күрми. Безнең тыныч-имин тормыш өчен тырышкан әби-бабайларыбызга карата игътибарлы һәм хөрмәтле булсак иде.

# Гарипова Равия   Харисовна



Гарипова Рәвия Харис кызы 1931 нче елның 21 декабрендә Саба авылында  дөньяга килә.

Рәвия Харис кызы гаиләдә 5 бала тәрбияләнәләр. Сугышта аларның әтиләре катнаша. Зәхмәтле сугыш кырыннан исән- сау әйләнеп кайтырга насыйп була аңа. Ул чорда Рәвия Харис кызына10 яшь була, шуңа карамастан ул өй эшләрендә, амбарларда хезмәт күрсәтә.1954 елдан бирле Сабаның СанПиН дезинфекция бүлегендә эшли, һәм 1993 елда лаеклы ялга чыга.

Бүгенге көндә Сабада тормыш иптәше Мәүлет, балалары Рәшит, Нурия, Илгизәр, туганнары, оныклары янында, кадерле Дәү әни булып яши.





# Сафин Тимерҗан Галәүтдин улы



Сафин Тимерҗан Галәүтдин улы 1927 елның 22 мартында Саба районы Йосыф-Алан авылында дөньяга килә.Башлангыч белемне Юлбат мәктәбендә ала һәм укуын Сатыш мәктәбендә дәвам итә.7 сыйныф белем белән тракторист белеме алырга Саба “МТС” җәмгыятенә языла.

Тракторист булып беренче хезмәт елларын Юлбат авыл җирлегендә башлап җибәрә,анда ул 1947 елга кадәр эшли.1948 елда Пермәчи шәһәренә шахтага эшкә китә.1949 елда Мамадыш районында машина йөртү таныклыгы алып, Шәмәрдән поселогында эшли башлый.

1952 елның 22 мартында ил алдында бурычын үтәргә армия сафларына хезмәт итәргә алына.4 елда 8 ай хезмәт итеп туган ягына кайтып Саба “МТС” җәмгыятенә механик булып эшкә урнаша.



1966 елда башкарма комитет приказы буенча коммуналь хуҗалык җитәкчесе итеп билгеләнә. 22 ел хезмәт куеп лаеклы ялга чыккач та бу өлкәдә эшен дәвам итә.







2010 елдан Саба районының Ветераннан Советы председателе булып билгеләнә.

Тормыш иптәше Әминә белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр,2 ул һәм 1 кыз.

**Әминә Батдал кызы** 1934 елның 15 маенда Чистай Шахмай авылында дөньяга киләә.7 класс белем алгач,1949 елда Чистай педагогия училищесына укырга керә.1952 елдан 1954 елга кадәр Таканыш районында эшли.

1954 елның 24 июленнән Саба районында балалар бакчасында эшен дәвам итә.

Тәрбияче вазыйфасын 35 ел башкарып 1989 елның 16 маенда лаеклы ялга чыга.








# Галиева Рәисә Тимершаех кызы





Галиева Рәисә Тимершаех кызы 1924 нче елның 20 нче сентябрендә Саба районы Көек авылында туган. Ул еллардагы бик күп гаиләләргә кагылган сугыш афәте аларны да читләп үтми. Әтиләре Тимершаехның колагы ишетмәсә дә, сугышка китә, аннан исән кайтырга насыйп булмый аңа. Ачлык, ялангачлык, авыр хезмәткә әле түзеп була. Иң аянычы – әтинең сугышта үлеп калуы, синең ятим балага әйләнеп, әтиле балаларга кызыгып яшәвең дип күз яшьләре белән сөйли әби. Сугышка киткәнче әтисе басуда ат җигеп сука сукалый, әнисе басуда кул белән көлтә ясап, чүмәлә куеп, урак ура, көз көне шобагач белән суга иде, дип искә ала әби. Сугыш башланганда Рәисә әбигә 17 яшь була. Аны зур кыз буларак, төрле эшләргә йөртә башлыйлар. Тылдагы авыр хезмәтләрнең берсе - урман кисүгә аны да җибәрәләр. Явлаштау һәм Килдебәк, Мишәбаш якларында урман кистек дип сөйли ул. Апас ягында окоп казырга җибәрделәр дип искә ала ул. Аннан кайтып берничә көн өйдә кунгач, Кемерова якларына вагон төяргә алып китәләр. Әби сугыш вакытында авылда тормый да. Авылда калган кызларны тракторда йөрергә өйрәттеләр, ди. Сугыш беткән көнне дә әби Кемерова якларында каршылый. Аннан ул 1946нчы елның августында гына кайттым дип сөйли.

Сугыш бетеп дөньялар тынычлана төшкәч, әби Көек авылы егете, сугышта катнашып, аннан исән-сау туган авылына кайткан, Галиев Шәйхелислам Гали улына-бабабызга 1950нче елда кияүгә чыга. Бабай разведкада була, ул взвод командиры ярдәмчесе булып хезмәт иткән. Ул чакта икебез дә авылда эшли башлаган идек, ди әби. Бабай – авыл советында секретарь, әби – чеби карый башлаган вакыт, кулга әзрәк акча да бирә башлаган чор була. Әби кияүгә чыкканда каралты-куралар әле һаман салам түбәле еллар. Соңрак бабай XXII партсъезд исемендәге колхозда зоотехник булып эшли. 40 яшь тулганда Тимершык мәктәбе каршындагы кичке мәктәптә урта белем ала. Аннан соң колхозлар һәм совхозлар өчен җитәкче кадрлар хәзерләү буенча бер еллык мәктәп тәмамлый.

булып эшли. 40 яшь тулганда Тимершык мәктәбе каршындагы кичке мәктәптә урта белем ала. Аннан соң колхозлар һәм совхозлар өчен җитәкче кадрлар хәзерләү буенча бер еллык мәктәп тәмамлый. Әби колхозда пенсиягә чыкканчы чеби, сарык карый, аларны көтә. Рәисә әби авылда оста умартачы булып танылa. Бакчадагы буш корт оясына килеп кергән кортлардан башланган бу шөгыль киңәя-арта. Әби үзлегеннән өйрәнеп умартачылык белән шөгыльләнә башлый, күбәйтә. Ул кортларны үзе карый. Бал аерган көнне авылдагы бөтен бала-чага җыела иде дип искә ала ул. Күршеләренә күчтәнәчкә тарата. Көек авылы ул чакта зур авыл, хәзергегә караганда урамнар күбрәк була.

Рәисә әби белән Шәйхи бабайның 4 баласы туа: Рәзилә, Кәбир, Әнисә, Мөнир. Ләкин Кәбир исемле малае 1998нче елны вафат була. Бүгенге көндә 3 баласы да үз гаиләләре белән Сабада яши, 10оныгы, 14 оныкларының балалары үсеп килә. Шәйхи бабай сугыш яраларыннан 60 яшендә вафат була. 91яшьлек Рәисә әби бүгенге көндә Сабада яши. Ирләре сугышта булганнарга торак бирү программасы буенча аңа 2010нчы елда яңа фатир бирелде. Мең рәхмәт Сезгә, тыл ветераннары!!!



Бу мәгълүматны
Сәләтле балалар мәктәбенең
1 нче сыйныф укучысы
Шафикова Әдилә Марат кызы тапшырды,
2016 нчы ел, апрель

# Гыйззәтуллина Нәкыя Маннановна



Нәкыя Маннан кызы Саба районы Байлар Сабасы авылында 1930 елның 25нче июнендә,гаиләдә 4 нче бала булып дөньяга килгән. Бүгенге көндә кече улы гаиләсендә Байлар Сабасы бистәсендә яши.

Балачак еллары авыр сугыш елына туры килә. Гаиләдә алар 5 бала, әтиләре Герман сугышында ук катнашып вафат була. Бөек Ватан сугышында олы абыйсы катнаша, тик исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп булмый аңа.

Нәкыя Маннан кызы 5 сыйныф белем алгач Мишәбаш урманын кисүгә алына. Киергә җылы кием,ашарга ризык булмауга карамастан, бер генә көнгә дә эш кимеми. Соңрак аны Сабабаш урманын кисүгә куялар. Бу вакытта Нәкыя Маннан кызына 17 яшь була.

1946 елда ул Казан шәһәрендә,хәзерге вакыттагы елга портындагы такта заводына эшкә керә. 1947 елда Байлар Сабасына ,”Гимн”колхозына эшкә урнаша.

Нәкыя Маннан кызы тормышка чыгып,1 ел гына бергә яшәргә насыйп була,тормыш иптәше юл һәләкәтенә очрап вафат була. 1973 елда Әлхәм абый белән гаилә корып җибәрәләр. Бер-бер артлы 2 малайлары дөньяга килә.











“Баш иябез Бөек елларга”

# Йосыпова ( Нурисламова) Гөлсылу Нурисламовна





Гөлсылу  Нурислам кызы 1931 елның 10 гыйнварында, гаиләдә 3 нче бала булып Саба районы Оет авылында дөньяга килә.

Әтиләре Нурислам сугышта катнашып вафат була.Әниләре бер үзе 3 бала тәрбияләп үстерә. 4 сыйныф белем алгач Гөлсылу Нурислам кызы Шәмәрдән урманы кисүдә алына.

Сугыштан соңгы елларда Байлар Сабасы авылында тегүче булып эшли башлый.





Тормыш иптәше Ханиф абый белән Оет авылында гаилә корып җибәрәләр. 3 бала тәрбияләп үстерәләр.1960 елда Байлар Сабасы авылында йорт салалар,Ханиф абый инде вафат . Гөлсылу Нурислам кызы хәзерге вакытта Байлар Сабасы бистәсендә яши.








“Баш иябез Бөек елларга”

Җиңү килде илне сөендереп,
Балкып атты матур җиңү таңы.
Исән булсын әле, Ветераннар!
Яшәсеннәр әле тагы, тагы!!!

Күкләребез мәңге аяз булсын,
“Уф” дип алмыйк әле сулышны
Көннәребез тыныч үтсен берүк,
Беркайчан да күрмик сугышны.....

**Бу хәтер альбомын**
**муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе “Аерым фәннәрне тирәнтен үзләштерүче сәләтле балалар мәктәп – интернат” коллективы эшләде.**

Төп җаваплы:
Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары А.Ш.Димөхәммәтова
Педагог – оештыручы Г.Н.Гыйззәтуллина

**Ш.т.б. Байлар Сабасы**

**Май, 2016 нчы ел**